СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2020 с. Сарманово № 222

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы «Сарман муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 16 февралендәге 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы таләпләре нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2015 елның 16 февралендәге 191 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Карарның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сарман муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләре исемлеген расларга (2 нче кушымта).»

2) 1 пунктның беренче абзацында «Сарман муниципаль районы» сүзләреннән соң сүзләр өстәргә: « (1 нче кушымта).»

3) «Кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга.

4) Карарга Сарман муниципаль районы махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләре исемлеген кушымта нигезендә өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» ( PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында , шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология мәсьәләләре һәм Сарман муниципаль районы Советының инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин

Татарстан Республикасы«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 6 февралендәге 222 номерлы карарына
2 нче кушымта

Сарман муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләре исемлеге

1. Җирле үзидарә органнарына сайлау вазыйфаларына сайланганнар;
2. Муниципаль хезмәткәрләр, башка хезмәткәрләр һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре;
3.Сарман муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре;
4.Сарман муниципаль районы эчке эшләр бүлекчәләре хезмәткәрләре;
5.Сарман муниципаль районы муниципаль предприятиеләре хезмәткәрләре;
6.Сарман муниципаль районы муниципаль учреждениеләре шактый ихтыяҗны кичерә торган белгечлекләр (вазыйфалар) хезмәткәрләре, шулай ук муниципаль учреждениеләр чакыруы буенча эшкә башка шәһәрдән килгән гражданнар:
- сәламәтлек саклау;
- мәгариф;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре;
- мәдәният;
- спорт;
- яшьләр.

7. Гамәлдәге торак законнарында каралган биналар бирелергә тиеш гражданнар.